КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 март г.Казань № 226

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар мониторингы турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1090 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар мониторингын гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар мониторингы турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1090 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар мониторингын гамәлгә ашыру тәртибенә, аны бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 декабрь, 1090 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 март, 226 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен
товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар мониторингын гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Бу Тәртип «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар мониторингын (алга таба – мониторинг, Федераль закон) гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

2. Бу Тәртиптәге төшенчәләр Федераль закондагы кебек үк мәгънәләрдә кулланыла.

3. Мониторинг Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан тәэмин ителә.

4. Мониторинг үткәрү кысаларында түбәндәгеләргә анализ ясала:

контрактның башлагыч (максималь) бәясе 50,0 млн сумнан артыграк булган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларга;

Дәүләт комитетының карарлары буенча башка сатып алуларга.

5. Мониторинг түбәндәге мәгълүматны җыю, гомумиләштерү, системалаштыру һәм бәяләү юлы белән даими нигездә гамәлгә ашырыла:

сатып алуларны башкару турында, шул исәптән сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында (алга таба – бердәм мәгълүмат системасы) булган сатып алуларның план-графикларын гамәлгә ашыру турында;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, оешмалардан, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләрдән, юридик затлар берләшмәләреннән, гражданнардан (дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләре үтәлешенә җәмәгатьчелек контроле нәтиҗәләрен кертеп) Дәүләт комитетына керә торган хатларда һәм мөрәҗәгатьләрдә булган;

сатып алуларны гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы булган һәм закон көченә кергән суд актлары турында;

башка ачык чыганакларда булган.

6. Мониторинг һәр квартал йомгаклары буенча һәм календарь ел йомгаклары

буенча гамәлгә ашырыла.

7. Дәүләт комитеты, мониторингны оештыру максатларында, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, эксперт оешмалары, иҗтимагый берләшмәләр һәм юридик затлар берләшмәләре, шулай ук башка органнар һәм оешмалар вәкилләреннән эшче төркемнәр төзергә хокуклы.

8. Мониторингны гамәлгә ашыру максатларында, Дәүләт комитеты Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар турындагы түбәндәге мәгълүматны куллана:

а) сатып алуларның план-графикларын тормышка ашыру турында, шул исәптән:

сатып алуларны гамәлгә ашыру турында урнаштырылган белдерүләр саны турында, тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү ысуллары буенча аерып, әлеге белдерүләрдәге тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү буенча гамәлгә ашырылмаган дип танылган процедуралар йомгаклары буенча бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, үтәүче) белән төзелә торган контрактларның башлангыч (максималь) бәяләренең, контрактлар бәяләренең суммар мәгънәсе турында;

тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү буенча гамәлгә ашырылган процедуралар саны турында, тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү ысуллары буенча аерып, мондый процедураларны үткәрү турындагы белдерүләрдә күрсәтелгән контрактларның башлангыч (максималь) бәяләренең суммар мәгънәсе турында;

тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү буенча гамәлгә ашырылмаган дип танылган, контракт төзүгә китермәгән процедуралар саны турында һәм, тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү ысуллары буенча аерып, сатып алуларны гамәлгә ашыру турындагы белдерүләрдәге контрактларның башлангыч (максималь) бәяләренең суммар мәгънәсе турында;

б) контрактлар реестрын алып бару турында, шул исәптән:

тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү ысуллары буенча аерып, Федераль закон нигезендә тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү буенча гамәлгә ашырылган процедуралар нәтиҗәләре буенча заказчылар тарафыннан төзелгән контрактларның саны һәм кыйммәте турында;

бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, үтәүче) белән контрактлар төзү өчен нигезләр буенча бүлеп, Федераль закон нигезендә бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән) сатып алу нәтиҗәләре буенча, шул исәптән тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү буенча гамәлгә ашырылмаган процедуралар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен заказчылар тарафыннан төзелгән контрактларның саны һәм гомуми кыйммәте турында;

Федераль закон нигезендә өзү өчен нигезләр буенча аерып, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән, Федераль закон нигезендә өзелгән контрактларның саны һәм гомуми кыйммәте турында;

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактларның үтәлеше турында, шул исәптән контрактлар өчен түләү турында, контрактта каралган йөкләмәләрне үтәмәү яки

тиешенчә үтәмәүгә бәйле рәвештә неустойкалар (штрафлар, пенялар) исәпләү турында;

в) намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) реестрын алып бару турында, шул исәптән, әлеге реестрга кертү өчен Федераль закон белән билгеләнгән нигезләр буенча аерып, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) реестрына кертелгән сатып алуда катнашучылар саны турында;

г) шикаятьләр реестрын алып бару, план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында, шул исәптән:

Федераль закон таләпләре нигезендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашырганда сатып алулар өлкәсендәге контроль органнары тарафыннан заказчы, вәкаләтле орган, вәкаләтле учреждение, махсуслаштырылган оешма, сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия, аның әгъзалары, контракт буенча хезмәтнең вазыйфаи заты, контракт буенча идарә итүче, электрон мәйданчык операторы гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне карап тикшерү саны һәм нәтиҗәләре турында;

Федераль закон белән билгеләнгән тикшерү объектларына карата үткәрелгән план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр саны һәм нәтиҗәләре турында;

заказчы, вәкаләтле орган, вәкаләтле учреждение, махсуслаштырылган оешма, электрон мәйданчык операторы яки сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия тарафыннан сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү турында, шул исәптән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, үтәүчеләрне) билгеләүне юкка чыгару турында бирелгән күрсәтмәләрнең саны хакында.

9. Мониторингны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр формалаштырыла:

бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән системалаштырылган мәгълүматны үз эченә алган кварталлык аналитик хисаплар;

бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән системалаштырылган мәгълүматны үз эченә алган җыелма аналитик хисап, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, кирәк булуга карап, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү чаралары.

10. Җыелма аналитик хисап түбәндәгеләр турындагы мәгълүматны үз эченә ала:

сатып алуларны планлаштыру;

сатып алуларны гамәлгә ашыру;

сатып алулар өлкәсендә контроль нәтиҗәләре;

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү;

кирәк булуга карап, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә

контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү чаралары.

11. Җыелма аналитик хисап календарь ел йомгаклары буенча әзерләнә.

12. Җыелма аналитик хисапны әзерләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

бу Тәртип нигезендә мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, системалаштыру һәм бәяләүне;

хисап елының 1 февраленә кадәр бүлекләр, бүлекчәләр һәм кушымталар исемен үз эченә алган җыелма аналитик хисап структурасын эшләүне;

җыелма аналитик хисап эшләүне һәм хисап елыннан соң килә торган елның 31 мартына кадәр аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне.

13. Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында кварталлык аналитик хисапларны урнаштыру хисап кварталыннан соң килә торган айның соңгы көненә кадәр (хисап елының соңгы кварталы өчен – хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр), җыелма аналитик хисап – хисап елыннан соң килә торган елның 15 апреленә кадәр гамәлгә ашырыла.